КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 19 ноябрь г.Казань № 1051

Татарстан Республикасында бердәм гомумроссия номерлы балалар ышаныч телефоны эшчәнлеген тәэмин итү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында бердәм гомумроссия номерлы балалар ышаныч телефоны эшчәнлеген тәэмин итү турындагы нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасында бердәм гомумроссия номерлы балалар ышаныч телефоны эшчәнлеген оештыру буенча вәкаләтләрне Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына йөкләргә.

3. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы мәсьәләләре» 2018 ел, 11 июль, 563 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә тиешле үзгәрешләр кертү хакындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына бу карарны тормышка ашыруны тәэмин итә торган оештыру карарларын кабул итүне тәкъдим итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 19 ноябрь, 1051 нче
карары белән расланды

# Татарстан Республикасында бердәм гомумроссия номерлы балалар ышаныч телефоны эшчәнлеген тәэмин итү турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмә Тормышта авыр хәлдә калган балаларга ярдәм күрсәтү фонды һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелгән Татарстан Республикасы территориясендә балалар ышаныч телефоны (ашыгыч психологик ярдәм күрсәтү хезмәте) эшчәнлеген тәэмин итү турындагы 2010 елның 24 августындагы 8/03 номерлы килешү (алга таба – килешү) нигезендә оештырылган Татарстан Республикасында бердәм гомумроссия номерлы балалар ышаныч телефоны (алга таба – балалар ышаныч телефоны) эшчәнлеген җайга сала.

1.2. Балалар ышаныч телефоны эшчәнлеге Берләшкән Милләтләр Оешмасының Бала хокуклары турындагы конвенциясе нормаларына, Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы законнарына, шул исәптән бу Нигезләмәгә нигезләнә, Халыкара телефон ашыгыч ярдәме күрсәтү федерациясе (IFOTES) һәм Халыкара балалар ышаныч телефоннары берләшмәсе (CHI) принципларын куллана.

1.3. Балалар ышаныч телефоны эшчәнлеген яраштыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты (алга таба – яраштыручы) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.4. Балалар ышаныч телефоны эшен оештыру Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә гамәлгә ашырыла.

## 2. Балалар ышаныч телефонының эш максаты һәм юнәлешләре

2.1. Балалар ышаныч телефоны эшчәнлеге балаларга, аларның ата-аналарына яки башка законлы вәкилләренә, балалар мәнфәгатьләрендә эш алып баручы затларга, нинди ведомствога каравына бәйсез рәвештә, балалар белән эшләүче белгечләргә телефоннан аноним ашыгыч консультация-психологик ярдәм күрсәтү максатларында, шул исәптән балаларга мөнәсәбәттә рәхимсез мөрәҗәгать ителгән һәм көч кулланылган очракларда (гаиләдә дә, гаиләдән читтә дә сексуаль көч кулланылган очракларны кертеп) гамәлгә ашырыла.

2.2. Балалар ышаныч телефонының эш юнәлешләре:

кризис шартларында, шул исәптән үз-үзенә кул салу куркынычы булган очракларда балаларга, аларның ата-аналарына яки башка законлы вәкилләренә, балалар мәнфәгатьләрендә эш алып баручы затларга телефоннан ашыгыч психологик ярдәм күрсәтү;

Татарстан Республикасы территориясендә балалар ышаныч телефоны эшчәнлеген популярлаштыруга, тормышта авыр хәлдә калган балалар шалтыратуларны мотивацияләүгә, балаларның, аларның ата-аналарының яки башка законлы вәкилләренең һәм кызыксынучы гражданнарның эчкечелекне, наркоманияне, тәмәке тартуны, хокук бозуларны, суицидаль тәртипне, башка социаль тискәре күренешләрне профилактикалау мәсьәләләрендә психологик грамоталылыгын арттыруга, балаларның һәм аларның ата-аналарының яки башка законлы вәкилләренең психологик культурасы дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән мәгълүмати-агарту эшчәнлеге;

балалар ышаныч телефоны хезмәткәрләренең эмоциональ януын профилактикалауга, һөнәри компетенцияләрне арттыруга, һөнәри күнекмәләрне камилләштерүгә, инновацион эш тәҗрибәсен гомумиләштерүгә һәм таратуга (балалар хокукларын яклау мәсьәләләре буенча профилактика программаларын/проектларын, семинарлар, түгәрәк өстәлләр, мәгълүмати материаллар әзерләүгә, тикшеренү материалларын эшкәртүгә) юнәлдерелгән методик эшчәнлек.

3. Балалар ышаныч телефоны эшен оештыру

3.1. Татарстан Республикасы территориясендә балалар ышаныч телефоны эшләвен тәэмин итү өчен килешүдә күрсәтелгән төрле ведомство карамагындагы оешмаларны яки аларның структур бүлекчәләрен бердәм гомумроссия номерына тоташтыру гамәлгә ашырыла.

3.2. Яраштыручы балалар ышаныч телефоны эшчәнлеген норматив хокукый җайга салуны, балалар ышаныч телефоны хезмәтләреннән һәркем файдалана алуны тәэмин итә.

3.3. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы:

балалар ышаныч телефоны эшчәнлегенең мәгълүмати-реклама кампаниясен оештыра;

балалар ышаныч телефоны белгечләренә белем алуда ярдәм күрсәтә, аларның эшчәнлегенә методик булышлык күрсәтә;

бала хокукларын яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппараты, Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынучы башкарма органнары, оешмалар һәм коммерциягә карамаган оешмалар белән ведомствоара хезмәттәшлекне оештыра;

балалар ышаныч телефоны эше турында хисаплар җыя һәм аларны гомумиләштерә һәм Тормышта авыр хәлдә калган балаларга ярдәм күрсәтү фондына җибәрә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, балалар ышаныч телефоны күрсәтә торган хезмәтләрнең сыйфатын тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

3.4. Балалар ышаныч телефоны эшчәнлеге түбәндәгеләрне тәэмин итә:

телефоннан, шул исәптән балаларга мөнәсәбәттә рәхимсез мөрәҗәгать ителгән һәм көч кулланылган очракларда (гаиләдә дә, гаиләдән читтә дә сексуаль көч кулла-

нылган очракларны кертеп) сыйфатлы итеп аноним ашыгыч консультация-психологик ярдәм күрсәтүне;

балалар ышаныч телефонына шалтыратуларны исәпкә алып бару;

квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 5енә кадәр кадәр балалар ышаныч телефоны эше турындагы хисапны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресына килешү кысаларында бирелгән форма буенча бирүне;

балалар ышаныч телефонын квалификацияле белгечләр белән комплектлауны;

балалар ышаныч телефоны эше кысаларында кергән мәгълүматның конфиденциальлеген, шулай ук балалар ышаныч телефонына мөрәҗәгать иткән затларның һәм балалар ышаныч телефонында эшләүче белгечләрнең шәхси мәгълүматлары сакланышын тәэмин итүне.

3.5. Балалар ышаныч телефоны эше, балаларны яклау хокукларын тәэмин итү таләпләрен исәпкә алып, яшьләр сәясәте, мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, мәгариф һәм медицина оешмалары, эчке эшләр органнары, шулай ук башка кызыксынучы оешмалар белән хезмәттәшлектә гамәлгә ашырыла.